ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.08.2019 Олы Кайбыч авылы № 381

Мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсацион түләүләр бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатыннан, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2013елның 12 сентябрендә 524 номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсацион түләүләр бирү Тәртибенә «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче баланы карау өчен ата-аналар түләве өчен гражданнар чыгымының максималь рөхсәт ителгән өлеше" Таблицасын түбәндәге юл белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яшәү минимумыннан түбәнрәк (күпбалалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

2. Әлеге карар рәсми бастырылган (халыкка таратылган) көненнән үз көченә керә һәм 2020елның 1 гыйнварыннан чыгачак хокук мөнәсәбәтләренә карата тарала дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында һәм буенча http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматый рәсми порталында» урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А.Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров